# КАРАР

**« 16 » ноябрь 2024 ел № 12**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Каратай торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, 2024 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Апаз авыл җирлеге Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Һ.Такташ урамының 20а йортыннан Ашытбаш-Карадуган төбәк автомобиль юлына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау; Һ.Такташ урамының 21 йортыннан Ашытбаш-Карадуган төбәк автомобиль юлына кадәр юл өслегенең нигезен төзү һәм юл-урам челтәрен ташлы балчык белән каплау; Һ.Такташ, Г.Камал урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);

-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 53 граждан,

тавыш бирүдә катнашкан 41 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 41 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Каратай торак пунктында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2025 елда Апаз авыл җирлеге Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Һ.Такташ урамының 20а йортыннан Ашытбаш-Карадуган төбәк автомобиль юлына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау; Һ.Такташ урамының 21 йортыннан Ашытбаш-Карадуган төбәк автомобиль юлына кадәр юл өслегенең нигезен төзү һәм юл-урам челтәрен ташлы балчык белән каплау; Һ.Такташ, Г.Камал урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Каратай авылы, Һ.Такташ урамы, 16 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында, Арча муниципаль районының (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү Татарстан Республикасы Арча

муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов